| | |
|---|---|
| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.06.2026_ Казан шәһәре № 01-05/91-пр

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең «Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024

елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2024 елның 24 сентябрендәге 01-05/241-пр номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны (үзйөрешле машиналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, коралландыруның, хәрби һәм махсус техниканың тәҗрибә (сынау) үрнәкләреннән тыш) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

Җитәкче А.Ш.Борһанов

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 2024 елның 21 маендагы 01-05/145-пр номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең
01.06.2026 № 01-05/91-пр боерыгы редакциясендә)

# Үзйөрешле машиналар һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның үзйөрешле машиналарыннан, хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, сынау (тәҗрибә үткәрү) өчен коралландыру, хәрби һәм махсус техникадан тыш ) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Үзйөрешле машиналар һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның үзйөрешле машиналарыннан, хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, сынау (тәҗрибә үткәрү) өчен коралландыру, хәрби һәм махсус техникадан тыш ) дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган административ процедураларның стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген (алга таба – дәүләт хезмәте) билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – гражданнар, шәхси эшкуарлар, үзйөрешле машина яисә башка төр техника ияләре булган юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышаныч кәгазе нигезендә гамәл кылучы затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте категорияләр (билгеләр), мөрәҗәгать итүчеләр нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Үзйөрешле машиналар һәм аларга тагылмаларны (Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең, башка гаскәрләрнең, хәрби формированиеләрнең һәм органнарның үзйөрешле машиналарыннан, хәрби, махсус һәм башка төр техникасыннан, сынау (тәҗрибә үткәрү) өчен коралландыру, хәрби һәм махсус техникадан тыш ) дәүләт теркәвенә алу.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе (алга таба – Идарә).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Идарәнең территориаль бүлекләре (алга таба – Идарә бүлеге).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) техниканы дәүләт теркәвенә алу;

Әлеге нәтиҗә түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- дәүләт теркәве турында таныклык бирү;

- дәүләт теркәү билгесен бирү;

- башкарылган теркәү гамәлләре турында белешмәләрне техника паспортына кертү (техника паспортын биргәндә) яисә башкарылган теркәү гамәлләре турында белешмәләрне техниканың электрон паспортларының автоматлаштырылган системасына тапшыру (техниканың электрон паспортын биргәндә);

- техниканың электрон паспортын рәсмиләштерү һәм техниканың электрон паспортыннан өземтә бирү;

- «Транзит» дәүләт теркәү билгесен бирү, техникага милек хокукынраслый торган документларда тамгалар кую һәм мөрәҗәгать итүчегә «Транзит» теркәү билгесен бирү турында белешмәләрне техника паспортларына (техниканың электрон паспортларына) кертү, әлеге билгеләрнең сериясен, номерын, бирү датасын һәм гамәлдә булу вакытын күрсәтү.

2) «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы техниканың теркәү күрсәткечләренә үзгәрешләр кертү;

Әлеге нәтиҗә түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык бирү;

- башкарылган теркәү гамәлләре турында белешмәләрне техника паспортына кертү (техника паспортын биргәндә) яисә башкарылган теркәү гамәлләре турында белешмәләрне техниканың электрон паспортларының автоматлаштырылган системасына тапшыру (техниканың электрон паспортын биргәндә);

- техниканың электрон паспортыннан өземтә бирү, Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларның тагылмаларын исәпкә алуның һәм теркәүнең федераль дәүләт мәгълүмат системасында башкарылган теркәү гамәлләре турында реестр язуын теркәү.

3) техниканы теркәү исәбеннән төшерү;

Әлеге нәтиҗә түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- «Транзит» дәүләт теркәү билгесен бирү, техникага милек хокукын раслый торган документларда тамгалар кую һәм мөрәҗәгать итүчегә «Транзит» теркәү билгесен бирү турында белешмәләрне техника паспортларына (техниканың электрон паспортларына) кертү, әлеге билгеләрнең сериясен, номерын, бирү датасын һәм гамәлдә булу вакытын күрсәтү;

- техниканы исәптән төшерү турындагы белешмәләрне теркәү турындагы таныклыкка кертү, Тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларның тагылмаларын исәпкә алуның һәм теркәүнең федераль дәүләт мәгълүмат системасында башкарылган теркәү гамәлләре турында реестр язуын теркәү.

4) югалган яисә яраксыз хәлгә килгән теркәү документларының дубликатын бирү;

Әлеге нәтиҗә түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- үзйөрешле машинаның электрон паспортыннан өземтә;

- дәүләт теркәү билгесе;

- техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык.

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында реестр язуын теркәү зарурлыгы юк.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче түбәндәге ысуллар белән алырга мөмкин:

Идарә бүлекләренә шәхсән килгәндә яки почта аша җибәреп;

Бердәм портал, Республика порталы аша электрон документ рәвешендә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар Идарә бүлегенә кулдан, почта аша яисә электрон почта аша тапшырылса, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты гарызнамә һәм документлар Идарә бүлеге тарафыннан теркәлгән көннән алып тугыз эш көне тәшкил итә.

Әгәр дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарә бүлегенә Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша тапшырылган булса, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты эшләр номенклатурасы нигезендә гарызнамәгә номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып тугыз эш көне тәшкил итә, алар Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетта чагылдырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь срогы югалган яисә яраксыз хәлгә килгән теркәү документларының дубликатын бирү өлешендә тиешле гариза теркәлгән көннән алып өч эш көнен тәшкил итә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Регламентка 4 нче кушымта таблицасының 2 бүлегендә күрсәтелгән нигезләр барлыкка килгән очракта тукталып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләрне билгеләгән көннән соң, 30 календарь көннән артып китә алмый.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.5.1. Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә дәүләт пошлинасы Россия Федерациясе Салым кодексының $333^{33}$ статьясының 1 пунктындагы 36-40 пунктчасында билгеләнгән күләмнәрдә алына һәм Идарә сайтында урнаштырылган.

Дәүләт пошлинасы күләме турындагы мәгълүмат Бердәм порталда, Республика порталында һәм Идарә сайтында урнаштырылган.

Дәүләт пошлинасы түбәндәге күләмдә алына:

1. Үзйөрешле техниканы яки тагылманы теркәүгә алу:

дәүләт теркәү билгесен бирү – 1500 сум;

теркәү турында таныклык бирү – 500 сум;

үзйөрешле машина паспортына үзгәрешләр кертү – 350 сум.

2. Үзйөрешле машинаны яки тагылманы исәптән төшерү:

үзйөрешле машина паспортына үзгәрешләр кертү – 350 сум.

3. Үзйөрешле машина һәм башка төр техниканың электрон паспортын рәсмиләштерү, үзйөрешле машинаның һәм башка төр техниканың электрон паспортына үзгәрешләр кертү – 2000 сум;

4. Югалган яки яраксызга килгәне урынына алмашка транспорт чарасын теркәү турында таныклык бирү:

теркәү турында таныклык бирү – 500 сум;

үзйөрешле машина паспортына үзгәрешләр кертү – 350 сум.

5. Транспорт чараларының, шул исәптән югалганнары яисә яраксыз хәлгә килгәннәре урынына, «Транзит» дәүләт теркәү билгеләрен бирү:

чыгым материалларыннан металл нигездә әзерләнә торган – 800 сум;

чыгым материалларыннан кәгазь нигезендә әзерләнә торган – 300 сум.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә алдан тутырылган реквизитлар буенча башкарыла ала.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләгәндә мөрәҗәгать итүчегә түләү документының тутырылган яки өлешчә тутырылган, шулай ук тутырылган түләү документының күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә.

Түләү документында исәпләмәнең уникаль идентификаторы һәм түләүченең идентификаторы күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мөрәҗәгать итүчегә Бердәм портал, Республика порталы аша хәбәр ителә.

Түләнгән дәүләт пошлинасы, дәүләт пошлинасын түләгән затларның юридик яктан әһәмиятле гамәл кылудан баш тарткан очракта, әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне кылган (кыла торган) вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча тапшырылган документка Идарә бүлегенең вазыйфаи затының гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә

мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргәндә һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Идарә бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә почта аша, электрон почта аша килгән гарызнамә гарызнамә кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.7.2. Гарызнамәне Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гарызнамә биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гарызнамәнең җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гарызнамәнең теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Идарәнең рәсми сайтында (https://gtn.tatarstan.ru/), шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.9.1.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану һәм сыйфат күрсәткечләре Идарәнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://gtn.tatarstan.ru/), шулай ук Бердәм порталда, Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары:

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системалары:

дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы (ГИС ГМП);

тракторларны, үзйөрешле машиналарны һәм аларга тагылмаларны исәпкә алу һәм теркәүче федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

2.10.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә биргән

вакытта балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән алырга теләк белдергән булса, мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәтен күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен бирү мөмкинлеге каралмаган.

Балигъ булмаганга карата кәгазьдә документ рәвешендә рәсмиләштерелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү тәртибе, шул исәптән мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә аларны бирү ысуллары һәм сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән каралмаган.

2.10.4. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.10.5. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

3) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә, Идарә бүлеге, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гарызнамәне формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәнең һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан уртак гарызнамә җибәрүне күздә тоткан хезмәтләрне сорап мөрәҗәгать иткәндә, гарызнамәнең бер электрон рәвешен җибәрү мөмкинлеге;

3) гарызнамәнең электрон рәвеше күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

4) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гарызнамәнең электрон рәвешенә күрсәткечләрне ялгыш керткәндә һәм яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гарызнамә рәвешенә элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

5) Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында урнаштырылган белешмәләрдән һәм Бердәм порталда, Республика порталында бастырып чыгарылган белешмәләрдән файдаланып, мөрәҗәгать итүче белешмәләрне кертә башлаганчы гарызнамәнең электрон рәвешендәге кырларын тутыру;

6) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гарызнамә рәвешен тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

7) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гарызнамәләрне мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гарызнамәләр буенча – кимендә 3 ай дәвамында.

2.10.6. Гарызнамәне формалаштыру, гарызнамәне өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гарызнамәнең электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан тыш, бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.10.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Регламентның 3 нче кушымтасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгеләргә бүлгәләп:

1) мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган документлар һәм мәгълүмат;

2) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә рәвеше РФ Хөкүмәтенең «Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренә 1-2 номерлы кушымталарда билгеләнгән һәм әлеге Регламентка 8-9 номерлы кушымталарда китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) гарызнамәнең һәм электрон рәвештәге башка документларның законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган булуы;

2) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

3) мөрәҗәгать итүче булып тормаган затның мөрәҗәгать итүе;

4) мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән бер яисә берничә документның булмавы.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:

1) техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкны, дәүләт исәбеннән алынган техниканың паспортын югалту;

2) техниканы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның, техника паспортының, техниканың төп компонентларының дөреслегенә һәм аларның номерларының тапшырылган документларга туры килмәвенә шик туу;

3) тапшырылган документларның, дәүләт теркәү билгеләренең ялган билгеләрен, җитештерүче оешмалар тарафыннан техникага төшерелгән маркировканың үзгәрүен яисә юкка чыгуын ачыклау, шулай ук техниканың яисә техниканың төп компонентларының эзләүдә булуы турында белешмәләр булганда яисә тапшырылган документларның урланган документлар исәбендә булуы турында белешмәләр булганда.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) Машиналарны теркәү кагыйдәләре нигезендә дәүләт теркәвенә алынмый торган техниканы дәүләт теркәвенә алу турында гарызнамә белән мөрәҗәгать итү;

2) Машиналарны теркәү кагыйдәләре нигезендә мәҗбүри булырга тиешле документларның яисә белешмәләрнең булмавы;

3) тапшырылган документларның норматив хокукый актларда яисә норматив-техник документларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

4) гамәлдә булу вакыты чыккан документлар тапшыру;

5) тапшырылган (алынган) документларда (белешмәләрдә) каршылыклы яисә дөрес булмаган мәгълүмат булу;

6) Россия Федерациясе законнары нигезендә салынган тыюлар һәм (яисә) чикләүләр булу;

7) белешмәләрне караганда алынган документларның тапшырылган (алынган) документларга (белешмәләргә) туры килмәве;

8) исәпкә алу системасында дәүләт исәбеннән төшерелмәгән техниканы дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр булу (техниканы дәүләт теркәвенә алу турында гарызнамә белән мөрәҗәгать иткәндә);

9) техника паспортында утильләштерү җыемын түләү турында яисә утильләштерү җыемын түләмәү нигезе турында Россия Федерациясе законнарында каралган тамганың булмавы (утильләштерү җыемын түләү турында техника төренә һәм категориясенә карата таләп каралмаган очраклардан тыш);

10) «гамәлдәге» статусы булган техниканың электрон паспортында Россия Федерациясендә утильләштерү җыемын түләү турында яисә утильләштерү җыемын түләмәү нигезләре турында белешмәләр булмавы;

11) техниканың һәм (яисә) техниканың төп компонентының яисә тапшырылган документларның эзләтүдә булуы турында белешмәләр булуы;

12) техниканың һәм (яисә) техниканың төп компонентының маркировкаларын ялганлап ясау, яшереп калу, үзгәртү һәм (яисә) юкка чыгару нәтиҗәсендә техниканы идентификацияләү мөмкинлеге булмау;

13) техника паспортын рәсмиләштергән оешма – техниканы әзерләүче зат Евразия икътисадый берлеге әгъзалары булган дәүләтләрнең вәкаләтле органнары (оешмалары) һәм транспорт чараларын (транспорт чаралары шассиларын), үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы әзерләүче, транспорт чараларының (транспорт чаралары шассиларының), үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың паспортларын (электрон паспортларын) рәсмиләштерүне гамәлгә ашыручы оешмаларның бердәм реестрына кертелмәгән яисә техника паспорты рәсмиләштерелгән техниканың ярашлылыгын бәяләү турындагы документ хакындагы белешмәләр әлеге оешма - техниканы әзерләүче затка карата күрсәтелгән бердәм реестрга кертелмәгән очракта (беренче тапкыр теркәлә торган техникага карата).

14) югалган яисә бозылган теркәү документлары урынына дубликат биргән өчен дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат булмау.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында мәгълүмат, баш тартуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеге күрсәтелеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең туры килмәве дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән исемлеген күрсәтеп җибәрелә.

2.12.5. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) Идарәнең электрон почтасы адресына почта аша (gostehnadzorrt@mail.ru) яки Идарә бүлегенә мөрәҗәгать итеп, ирекле рәвештә язылган язма гарызнамә нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында гарызнамә нигезендә Идарә бүлегенең вәкаләтле вазыйфаи заты дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә. Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкиленең) гарызнамәсен теркәп һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карар белән дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту факты «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында теркәлә.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүчегә караган объектлар һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту)

турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш);

5) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

6) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерү мөрәҗәгать итүчегә анкета бирү юлы белән башкарыла, аның барышында мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) билгеләнә.

Мөрәҗәгать итүченең категорияләрен (билгеләрен) билгеләү әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүченең категорияләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла, аның барышында мөрәҗәгать итүченең билгеләре күрсәткечләренең тулы исемлеге билгеләнә, аларның һәркайсы мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу өчен тапшырырга тиешле документларның билгеле бер исемлегенә туры килә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

3.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә рәвеше РФ Хөкүмәтенең «Үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләренә 1-2 номерлы кушымталарда билгеләнгән һәм әлеге Регламентка 8-9 номерлы кушымталарда китерелгән.

Мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат исемлеге, шулай ук күрсәтелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматны бирү ысуллары әлеге Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү (идентификацияләү) ысуллары булып мөрәҗәгать итүчеләр белән үзара хезмәттәшлек иткәндә түбәндәгеләр тора:

а) Идарә бүлекләрендә – мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документы;

б) Бердәм портал, Республика порталы ярдәмендә – Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза, тикшерү ачкычы сертификаты электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган көчәйтелгән квалификацияләнмәгән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан тәртип буенча электрон имза.

3.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.3.4. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яки тору урынына (гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә күрсәтелә.

3.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне һәм документларны теркәү вакыты:

Идарә бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә почта аша, электрон почта аша килгән гарызнамә гарызнамә кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә;

гарызнамәне Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гарызнамә биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша гарызнамәнең җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гарызнамәнең теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

3.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек.

3.4.1. Гарызнамәләрне җибәрү өчен нигез булып Идарә бүлегендә теркәлгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә һәм мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентка 3 нче кушымта таблицасының 2 бүлегендә күрсәтелгән документларны тапшырмавы тора.

Әлеге органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Дәүләт хезмәтен алу өчен Идарә бүлегенең вазыйфаи заты тарафыннан «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамә теркәлгән көннән алып бер эш көне дәвамында түбәндәге ведомствоара мәгълүмат гарызнамәләре җибәрелә:

1) Таможня берлеге комиссиясенең 2011 елның 18 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган техниканың Таможня берлегенең «машиналар һәм җайланмалар иминлеге турында» техник регламенты һәм (яисә) Евразия икътисадый комиссиясе советының 2012 елның 20 июлендәге 60 номерлы карары белән расланган Таможня берлегенең «Авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы тракторларының һәм аларга тагылмаларның иминлеге турында» техник регламенты таләпләренә туры килүен бәяләү хакында гамәлдәге документ. Әлеге мәгълүмат гарызнамәсе Аккредитация буенча федераль хезмәткә җибәрелә;

2) «Транспорт чарасы хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү иминият полисы». Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерүнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасының вәкаләтле операторына – «Российский Союз Автостраховщиков» коммерциясез оешмасына җибәрелә;

3) «Дәүләт пошлинасын түләү турында квитанция (түләү йөкләмәсе) һәм/яисә Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе түләүләре өчен түләү факты турында белешмәләр». Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе «Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә җибәрелә;

4) «Техниканы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык». Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе Россия Федерациясе дәүләт техник күзәтчелек органнарына җибәрелә;

5) «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә». Әлеге мәгълүмат гарызнамәсе Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

6) «Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә». Әлеге мәгълүмат гарызнамәсе Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

7) «Транспорт чараларының электрон паспортлары (транспорт чаралары шасси паспортлары) системасының һәм үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең электрон паспортлары системасы» автоматлаштырылган системасында «гамәлдәге» статусы булган техниканың электрон паспортыннан өземтә». Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе электрон паспортлар системасында үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың электрон паспортлары системаларының вәкаләтле администраторына – «Электронный паспорт» АҖ гарызнамә кергән көнне җибәрелә;

8. «Салым түләүченең идентификация номеры турында мәгълүмат». Әлеге мәгълүмат гарызнамәсе Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

9) «Хосусый шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС)». Күрсәтелгән мәгълүмат гарызнамәсе Россия Федерациясенең Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә.

3.4.2. Әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гарызнамәне юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда. Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гарызнамәләргә җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара

гарызнамә алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәү мәсьәләсенә бәяләү (дәүләт хезмәтен күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) (алга таба – бәяләү процедурасы).

3.5.1. Хезмәт күрсәтү өчен үзйөрешле машинаны карау, үзйөрешле машинаның завод, идентификация номерын яисә үзйөрешле машинаның төп компоненты номерын үзгәртү, яшерү, юкка чыгару билгеләренең булмавын тикшерү процедурасы үткәрелә:

а) бәяләү процедурасының дәвамлылыгы ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар кергән көннән алып биш эш көнен тәшкил итә;

б) бәяләү процедурасын үткәрүче субъект – Идарә бүлеге;

в) бәяләү процедурасы объекты – мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең дөреслеген раслаучы гарызнамә һәм аңа беркетелә торган документлар, шул исәптән идентификацияне һәм транспорт чарасы конструкциясенең тапшырылган документларга туры килүен тикшерү, ә кирәк очракларда – транспорт чарасы конструкциясенә кертелгән үзгәрешләрнең транспорт чарасының аның конструкциясенә кертелгән үзгәрешләр белән куркынычсызлык таләпләренә туры килүе турындагы документларга туры килүен тикшерү.

3.5.2. Шушы Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне алганнан соң Идарә бүлеге вазыйфаи заты үзйөрешле машинаны дәүләт теркәвенә алу турында гарызнамә бирү урыны буенча яки үзйөрешле машина урнашкан урын буенча, ә техника төркемен караган очракта – үзйөрешле машиналар урнашкан урын буенча, үзйөрешле машинаны карарга чыгу турында карар кабул итә.

Идарә бүлеге вазыйфаи заты үзйөрешле машинаны билгеләнгән көнне үзйөрешле машиналарның тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килүен тикшерә һәм машинаны идентификацияли.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү.

3.6.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү ведомствоара гарызнамәләргә җаваплар алынган көннән алып җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.

3.7.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору турындагы карар, туктатып тору

сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 9 нчы кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул ителгән көнне мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) түбәндәге ысуллар белән бирелә (җибәрелә):

1) Идарә бүлекләренә шәхсән кергәндә яисә почта аша җибәрелгәндә кәгазьдә;

2) электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча һәм (яки) Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

3.7.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр билгеләнгәндә, түбәндәге административ гамәлләр гамәлгә ашырыла:

1) Идарә бүлеге вазыйфаи заты, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, үзйөрешле машинаны элеккеге дәүләт теркәве урыны буенча тапшырылган документларның тапшырылу фактын, шулай ук дөреслеген билгеләү өчен гарызнамә җибәрә;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору көнендә «Гостехнадзор Эксперт» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына дәүләт хезмәтен туктатып тору турында белешмәләр кертелә.

Әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәгә алынган җавапны анализлау нәтиҗәләре буенча Идарә бүлегенең вазыйфаи заты дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору сәбәпләрен бетерүне раслый торган документлар кергән көннән дәүләт хезмәтен күрсәтүне яңарту турында яисә  дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.7.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне яңарту турында карар, яңарту сәбәпләрен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен яңарту турында карар кабул ителгән көнне түбәндәге ысуллар белән бирелә (җибәрелә):

1) почта аша кәгазь чыганакта;

2) электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча һәм (яки) Бердәм порталда, Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

3.7.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләрне билгеләгән көннән соң, 30 календарь көннән артып китә алмый.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8.1 Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул ителгән көннән алып бер эш көненнән дә артмаган срокта һәм түбәндәге ысуллар белән гамәлгә ашырыла:

Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Идарә бүлегенә шәхсән кергәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать иткән көнне бирелә;

почта аша җибәрү юлы белән.

3.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яисә тору урынына (гражданнар һәм шәхси эшкуарлар өчен) яисә урнашу урынына (юридик затлар өчен) бәйсез рәвештә күрсәтелә.

3.9. Теркәү документлары югалган яисә бозылган очракта, Идарә бүлеге

мөрәҗәгать итүче гарызнамәсе буенча теркәү документларының дубликатын бирә.

Теркәү документларының дубликатын биргән өчен әлеге Регламентның 2.5.1 пунктының 4 бүлегендә күрсәтелгән күләмдә дәүләт пошлинасы алына.

Югалган яки бозылган теркәү документлары урынына дубликат бирү турындагы гарызнамәне теркәү административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Югалган яисә бозылган теркәү документлары урынына дубликат бирү өчен кирәкле гарызнамәне һәм документларны теркәү вакыты:

- Идарә бүлегенә, почта, электрон почта аша шәхсән мөрәҗәгать иткәндә кергән гарызнамә гарызнамә кергән көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә;

